ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» декабрь 2020 ел №402

«2020-2021 уку елына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәп маршрутларын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 03 августындагы 234 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләре өчен яңа автобуслар бирелү сәбәпле, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәктәп автобус маршрутын ачу турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 03 августындагы 615 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, белем бирү учреждениеләре укучыларын расланган маршрутлар буенча балаларны йөртү өчен махсус җайлаштырылган автобуслар белән даими һәм куркынычсыз йөртүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.«2020-2021 уку елына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәп маршрутларын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 03 августындагы 234 номерлы карарының 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- №6 «Тирсә-Яңавыл-Тирсә-Биектау-Тирсә, автобус Пежо Боксер, дәүләт номеры Т 417 ТУ (22 урын);»

1.2 8 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- №7 «Үтәгән-Нарат-Девятерня-Иске Эсләк-Кадыбаш- Үтәгән, автобус ГАЗ-322121, дәүләт номеры А 818 АЕ (11 урын);»

1.3. 9 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- № 8 «Үтәгән-Иске Эсләк-Касай-Кадыбаш-Үтәгән, яңа автобус Форд Транзит, дәүләт номеры АС 450 (22 урын);»

1.4. 10 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- № 9 «Кичкетаӊ-Баржы-Умга-Кичкетаӊ-Кырынды-Кичкетаӊ, яӊа автобус Форд Транзит, дәүләт номеры АС 913 (22 урын);»

1.5. 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- № 10 «Кичкетаӊ-Хор.Ключ-Кырынды-Кичкетаӊ-Баржы Пельга-Кичкетаӊ, автобус ГАЗ 322121, дәүләт номеры Е 761 МУ (11 урын);»

1.6. 12 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- № 11 «Тирсә-Бәзәкә-Яӊавыл- Вольный Труд-Тирсә-Нажар-Чишмә-Тирсә, автобус Форд Транзит, дәүләт номеры Х 054 ХР 9 (22 урын);»

1.7. 13 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- № 12 «Тирсә-Кодаш-Мордыбый-Тирсә-Туба-Тирсә, яӊа автобус Форд Транзит, дәүләт номеры АС 449 (22 урын);»

1.8. 14 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- №14 «Ямурза-Уразай-Салагыш-Уразай-Ямурза, яӊа автобус Форд Транзит, дәүләт номеры АС 912 (22 урын);».

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 03 августындагы 615 номерлы карары белән расланган Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмә таләпләре нигезендә мәктәп автобуслары маршрутлары паспортларын әзерләргә, килештерергә һәм расларга;

- мәктәп автобус маршрутлары реестрына тиешле үзгәрешләр кертергә;

- автобус хәрәкәтенеӊ күрсәтмә һәм дәрестән тыш вакытта графигын әзерләргә һәм ел саен анықларга;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге ЮХИДИ бүлеге белән килештереп, укучыларны утырту һәм төшерү пунктын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләренә балаларны уку урынына китергәндә һәм киресенчә алып кайтканда озату өчен җаваплы башкаручыларны билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарның 1 п. күрсәтелгән расланган мәктәп маршрутлары буенча автобусларда пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда укучыларның куркынычсызлыгын тикшереп торуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенеӊ беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**